ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 август, 2017 ел № 18/8

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләренә, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре проекты»н (алга таба – Шәһәр Советы карары проекты) хупларга һәм 1нче кушымта нигезендә гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Карар проекты буенча гавами тыңлауларны (алга таба - гавами тыңлаулар) үткәрү көнен 2017 елның 15 сентябренә, үткәрү вакытын 14:00 сәгатькә тәгаенләргә, гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында (Х.Туфан проспекты, 23 йорт) 400 залны билгеләргә.

3. Гавами тыңлаулар үткәрү буенча комиссия составын 2 санлы кушымтадагыча расларга.

4.Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ